ДЕПУТАТ
ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
ДЕПУТАТЫ

2009-2014

21.11.2011 № 3-21

На № __________ от _________

Дүртенче чакырылыш
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советының
егерме дүртенче утырышы
секретариатына

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Регламентының 186 статьясының 2 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советының егерме дүртенче утырышының көн тәртибенә кушымтада бирелгән депутат гарызнамәсен кертергә тәкъдим итәм.

Кушымта: 1 биттә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы депутаты А.Ш. Зыятдинов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ
АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
«21» 11 2011 г.
Керү
Вх. № 9113
ИНН 1654014349

ДЕПУТАТ
ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
ДЕПУТАТЫ

2009-2014

_______________ № _________

На № __________ от _________

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
И.Ш. Халиковка

Татарстан Дәүләт Советы
депутаты А.Ш. Зыятдинов
гарызнамәсе (запрос)

Авылларда башлангыч
мәктәпләрне саклау турында

Хөрмәтле Илдар Шәфкать улы!

Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов үзенең Татарстан Республикасы Дәүләт Советына 2011 елгы Юлламасында республиканың һәрбер торак пунктында башлангыч мәктәп булырга тиешлеген ассызыклады.

Шуңа да карамастан, республикабызда ябылган башлангыч мәктәпләр шул ябылган хәлендә калдылар. Мәгариф министрлыгыннан алынган мәгълүматларга караганда, быелгы уку елында Татарстанда 114 мәктәп ябыла. Шулар арасында күбесе башлангыч мәктәпләр. Мәсәлән, Балтач районында гына да 5 башлангыч мәктәп ябылды, ә тагын икесе ябылуга әзерләнеп, мөдирсез калдырылып, “филиал статусына” күчерелде, ике тугыз еллык мәктәп башлангычка, ике унбер еллык мәктәп тугыз еллыкка күчерелде (барысы 11 мәктәп!). Ә оптимизация нинди отыш бирде? Димәк, Президент күрсәтмәсе үтәлеше буенча бүгенге көнгә бернинди үзгәреш тә юк.

Хөрмәтле Илдар Шәфкать улы! Халыкка аңлашылмаган шушы хәлгә аңлатма бирсәгез иде.

Ихтирам белән,
2011 елның август ахырында ябылган, илебезгә 70 тән артык укытучы, өч Татарстан фәннәр Академиясе әгъзасы, уннан артык фән докторлары, кандидатлары, хөкүмәт җитәкчеләре, мәктәп директорлары, хуҗалык җитәкчеләре, инженерлар, атказанган хезмәткәрләр һәм башка күренекле шәхесләр биргән Таузар мәктәбенең элеккеге укучысы, техник фәннәр докторы, профессор, Татарстан фәннәр Академиясе әгъза-корреспонденты,

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы депутаты А.Ш. Зыятдинов